СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.10.2025 г. Заинск № 11

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2006 елның 01 мартындагы 1 номерлы «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасын төзү турында, муниципаль милек белән идарә итү, эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 һәм 39.15 статьяларына һәм «Геодезия, картография һәм пространство белешмәләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 18.1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 08 августындагы 317-ФЗ номерлы Федераль законы белән, «Пространство белешмәләренең милли системасы «Бердәм цифрлы платформасы» Федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 07 июнендәге 1040 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2006 елның 01 мартындагы 1 номерлы «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасын төзү турында, муниципаль милек белән идарә итү, эш итү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Зәй муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында Нигезләмәгә (27.09.2018 ел, №336 редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 4.1.8 пунктны өстәргә:

«4.1.8. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын, шулай ук пространство

белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын кулланырга.».

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, икътисадый үсеш һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**